Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 2 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Әлеге Закон "Этил спирты, алкоголь һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгели.

**2 статья**

1. Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату предприятиеләренә әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен 22.00 сәгатьтән алып 10.00 сәгатькә кадәр ваклап сату тыела, моңа әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очраклар керми.
2. Ресторannarда, барларда, кафеларда әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату оешманың эш режимы нигезендә гамәлгә ашырыла.
3. Алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы ваклап сату предприятиеләре әзер продукция күләменең 15 проценттан артыграгы этил спирты булган алкоголь продукциясен ваклап сату вакыты турындагы мәгълүмат белән сатып алучыларны тәэмин итәргә тиеш.

**3 статья**

Әлеге Закон таләпләрен бозу законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

**4 статья**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле үзидарә органнары әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң өч ай эчендә үз норматив хокукый актларын аңа туры китерергә тиеш.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 22 ноябре
№ 80-ТРЗ